ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
“АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ “
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район,
село Старые Киязлы, ул. Центральная д.57
Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 106166500233 2,
ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001

---

# РЕШЕНИЕ

№ 31 27 июнь 2022 нче ел

## Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы РФ Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, РФ Оборона министрлыгының 25.04.2009 елдагы 315/2/203 номерлы хаты һәм хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы **Иске Кыязлы** авыл җирлеге **Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләр хезмәтенә түләү турында Нигезләмәне расларга.

2.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http:// Aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольлегемдә калдырам.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Г.Г. Дәүләтшин

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының
2022 елның 27 июнендәге 31 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу белгечләренең хезмәт өчен түләү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**I. Гомуми нигезләмәләр.**

1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә җирлекнең беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәткә түләү тәртибен җайга сала.

3. Әлеге Нигезләмә хәрби исәпкә алу буенча белгечнең ярашлылык буенча вазыйфаларын башкаручы һәм хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә, беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хезмәт хакын билгеләгәндә кулланыла.

4. Хәрби-исәп хезмәткәре хезмәтенә түләү фонды, федераль бюджеттан җирлеккә бирелә торган субвенцияләр күләменнән чыгып, календарь елга төзелә.

5. Өстәмәләр күләме хезмәткә түләү өчен бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә билгеләнә.

**II. Хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары**

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы белгечләрнең хезмәт хакы әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла һәм айлык вазыйфаи окладтан (алга таба - вазыйфаи оклад), компенсация түләүләреннән һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Берлектә эшләүче хәрби исәпкә алу хезмәткәрләре өчен хәрби исәптә торучы гражданнар санына турыдан-туры пропорциональ сәгать атнасы билгеләнә.

3. РФ Оборона министрының «Россия Федерациясе хәрби частьләренең һәм Кораллы Көчләре оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында" 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, хәрби-учет хезмәткәренең вазыйфаи окладының күләме, инспектор окладына тиңләштерелгән окладтан алып түләнә.

| | |
|---|---|
| | Вазыйфаи оклад күләме, сум. |
| Исәпкә алу һәм броньлау буенча инспектор | 6552,00 |

4. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 282, 284, 285 статьялары нигезендә, бергәлек буенча вазыйфаларын башкаручы хәрби-учет хезмәткәренең вазыйфаи окладының максималь күләме азат ителгән хәрби-учет хезмәткәренең вазифа окладының 50% тан артмаска тиеш. Хәрби исәптә торучы гражданнар санын исәпкә алып, бергәлек буенча вазыйфаларын башкаручы хәрби-учет хезмәткәренә түбәндәге вазыйфаи окладлар билгеләнә::

– хәрби исәптә 400 гражданга кадәр булганда -азат ителгән хәрби-исәп хезмәткәренең вазифа окладының 40%.түләнә

5. Хезмәткәргә кызыксындыру характерындагы түбәндәге түләүләр башкарыла:

а) Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 18.09.2009 ел, №545 боерыгы нигезендә билгеләнгән тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә

Хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә эш стажына карап, әлеге өстәмәне алу хокукын бирә торган эш стажына карап түбәндәге күләмнәрдә дифференциацияләнгән рәвештә башкарыла:

| Хезмәт стажы | Күләме (вазыйфаи окладка карата процентларда) |
|---|---|
| 1 елдан артык | 5 |
| 2 елдан артык | 10 |
| 3 елдан артык | 15 |
| 5 елдан артык | 20 |
| 10 елдан артык | 30 |
| 15 елдан артык | 40 |

Эш стажын исәпләгәндә исәпкә алына торган, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү билгеләү хокукын бирә торган чорлар календарьда билгеләнә һәм суммалаштырыла. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алу хокукын бирүче эш (хезмәт) стажын билгеләү өчен төп документ булып хезмәт кенәгәсе (хәрби билет) тора. Эш (хезмәт) стажын раслап, хезмәткәр тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алу хокукын бирә торган эш (хезмәт) стажы булуын раслаучы башка документлар да тапшырылырга мөмкин. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә әлеге өстәмә билгеләү яки аның күләмен арттыру хокукы барлыкка килгән мизгелдән билгеләнә һәм түләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә күләмен вакытында яңадан карау өчен җаваплылык кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәркә йөкләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләү тиешле хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

б) вазыйфаи бурычларны намус белән башкарган өчен елга 2 вазыйфаи окладка кадәр акчалата бүләк;

в) эш нәтиҗәләре буенча вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә айлык премия.

Хезмәткәрләргә айлык премия эш күләмен сыйфатлы, оператив башкарган өчен түләнә.

г) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актларында каралган башка түләүләр.

6. Компенсация түләүләре үз эченә махсус климатик шартларда эшләгән өчен түләүләрне ала. Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 18.09.2009 ел, № 545 боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы өчен хәрби-учет хезмәткәренең хезмәт хакына район коэффициенты 1,15 тәшкил итә

### III. Хәрби исәпкә алучы белгечкә ял

Хәрби исәпкә алу буенча белгечкә ел саен 28 календарь көн дәвамында түләүле отпуск бирелә. Совместительство буенча эшләүче белгечләр өчен түләүле ял ел саен бирелә торган ял белән бер вакытта бирелә.